СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

25.12.2019 № 38/1
На № ________ от ____________

**Тукай муниципаль районында ветераннарның, өлкән яшьтәге гражданнарның социаль-икътисадый хәлен яхшырту, аларның сәламәтлеген ныгыту һәм актив озак яшәүгә ярдәм итү турында**

Тукай муниципаль районында ветераннарның, өлкән яшьтәге гражданнарның социаль-икътисадый хәлен яхшырту, аларның сәламәтлеген ныгыту һәм актив озак яшәүгә ярдәм итү турында мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мәгълүматны исәпкә алырга.
2. Район Башарма комитетына түбәндәге эшләрне дәвам итәргә:
- сугыш һәм хезмәт ветераннарының, пенсионерларның социаль-икътисадый тормыш шартларын яхшырту, аларның социаль якланганлык дәрәҗәсен арттыру, өлкәннәрнең җәмгыять тормышында катнашуын активлаштыру буенча;
- өлкән яшьтәге гражданнар арасында янгын һәм социаль куркынычсызлык чаралары буенча;
- Бөек Ватан сугышы ветераннарын, пенсионерларны, өлкән яшьтәге кешеләрне юбилей даталары (90 яшьтән башлап) һәм бәйрәм чаралары белән тәбрикләү буенча;
- өлкән яшьтәге гражданнарга медицина хезмәте күрсәтүнең сыйфатын күтәрү буенча эшне көчәйтергә, ташламалы категория гражданнарны дарулар белән тәэмин итү мәсьәләләрен даими контрольдә тотарга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары Р.И.Закиров